КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 апрель г.Казань № 527

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 924 нче карары белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 924 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 август, 818 нче; 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы; 2022 ел, 26 декабрь, 1417 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен махсус икътисадый зоналарның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 8 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процenttан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин